**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Кама Тамагы муниципаль районынын**
**Сойки авыл жирлеге**
**Башкарма комитеты**
**Кама Тамагы районы, Сойки авылы**
**тел. 8 (843) 77 36-3-38**
**РТ Камско-Устьинский район с. Сюкеево ул. Колхозная дом 16а**

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**Камско-Устьинский муниципальный район**
**Исполнительный комитет Сюкеевского сельского поселения**
**Камско-Устьинский район, с. Сюкеево**
**тел. 8 (843) 77 36-3-38**
**РТ Камско-Устьинский район с. Сюкеево ул. Колхозная дом 16а**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**2019 ел, 14 октябрь** **№11**

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Сөйки авыл җирлеге Башкарма комитетының 2018 елның 18 декабрендәге 29 номерлы «Адресларны бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» карары нигезендә адресларны бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

«Федераль мәгълүмат адреслы система турында һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законга үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 26 июлендәге 227-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Сөйки авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Сөйки авыл җирлеге Башкарма комитетының «Адресларны бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2018 елның 18 декабрендәге 29 номерлы карары белән расланган адресларны бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең

административ регламентына (алга таба-регламент) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.5 пунктта:

өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«адрес-Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыру принциплары нигезендә структуралаштырылган һәм үз эченә шул исәптән урам-юл челтәре элементының һәм (яки) планлаштыру структурасы элементының атамасы (кирәк булганда), шулай ук адресация объектының санлы һәм (яки) хәреф-цифрлы билгеләнешен ала торган адресация объектының урнашу урыны тасвирламасы.;»;

бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«адресация объекты-капиталь төзелеш объекты, җир кишәрлеге яки Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән адресация объектлары исемлеге белән каралган башка объект;».

2. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында игълан итәргә:

- ТР Кама Тамагы районы, Сөйки авылы, Кызыл Армия урамы, авыл үзәге;

- ТР Кама Тамагы районы, Сөйки авылы, Колхоз урамы, 16А йорты, китапханә бинасы,

шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга кирәк.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче В.П. Никитин